Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә якынча җаваплар (мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 5 нче сыйныф

Максималь балл – 38.

I. Теоретик биремнәр. (8 балл)

1. Халык авыз иҗатында җырларның нинди төрләре булуын әйтә аласыз? Санап чыгыгыз. (5 балл)

Кыска җырлар, тарихи җырлар, көйләре ягыннан – озын һәм кыска җырлар, эчтәлеге ягыннан – тарихи һәм лирик җырлар.

2. Түбәндә аталган җырларның кайсылары халык авыз иҗатына карый. (3 балл)

А) **“Гөлҗамал”**
Б) “Гармун”
В) **“Ай,былбылым”**
Г) “Туган тел”
Д) **“Кара урман”**

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (15 балл)

1. “Ак бүре” әкиятендә аллегорик образларга мөрәҗәгать ителә. Түбәндәге билгеләмәләрдә кем турында сүз баруын ачыклагыз һәм шул образларга чагыштырма характеристика бирегез. (10 балл)

1) “Ул – кара урманның кырыс һәм кодрәтле хуҗасы” **(Бүре)**

2) “Ул – Каф тавы артында яши һәм хакимлек итә, көчле һәм явыз зат” **(Дию)**

2. “Ак бүре” әкиятендә җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, геройлар, аларның эш-гамәлләре аша укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

Ярдәмчеллек, гаделлек, әдәплелек сыйфатлары теләсә нинди авырлыкны җиңеп чыгарга ярдәм итә һ.б.

III. Иҗади эш. (15 балл)

Кыз, куян, төлке, бүре образларын кертеп, кечкенә генә әкият языгыз.